ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«04» февраль 2025 ел № 84

**Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16нчы мартындагы “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы” 184нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасынң спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасының спорт әзерлеге буенча дәүләт үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында” 2018 елның 25нче сентябрендәге 853нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турындагы” 2024 елның 29 сентябрендәге 766нчы номерлы карарын үтәү йөзеннән Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16нчы мартындагы “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы” 184нче номерлы карарына (Арча муниципаль районының 2022 елның 22 декабрендәге 1126нчы, 2024 елның 8 маендагы 316нчы, 2024 елның 10нчы июлендәге 486нчы номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Арча муниципаль районында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“II. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

2.1. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура буенча инструктор | 22 663 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Оештыручы педагог | 22 758 |
| | Мөгаллим тренер | |
| | Инструктор-методист | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Педагог-психолог | 22 858 |
| | Өлкән мөгаллим тренер | |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлек: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту һәм консультация бирү пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм гомуми белем бирү программалары, балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф программалары тормышка ашырылган башка структур бүлекчәләр мөдире | 23 008 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Гомуми белем бирү программасы һәм балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф программасы тормышка ашырылган, аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | 23 058 |

2.2. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | 1 айга база окладлы күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| “Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 22 820 |
| “Төп звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | |
| Тавыш операторы | 23 320 |
| Бизәүче рәссам | |

2.3. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда медицина хезмәткәрләре вазыйфаларының база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база окладлары күләме, сум |
|---|---|---|
| "Урта медицина һәм фармацевтика персоналы" һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы (медицина абыйсы) | 23 121 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медицина абыйсы) | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы (өлкән медицина абыйсы) * | 24 821 |
| "Табиблар һәм провизорлар" һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрә-җәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән башка) | 26 521 |
| *Вазыйфа оешмада өч һәм аннан да күбрәк шәфкать туташлары (медицина абыйлары) буйсынуда булганда билгеләнә | | |

2.4. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база окладлары күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Спорт залы буенча кизү торучы | 21 200 |
| | I төркем инвалид спортчыга ярдәм күрсәтеп йөрүче | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Спортчы | 21 200 |
| | Әйдәп баручы спортчы | |
| Икенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Адаптацияли торган физик культура буенча инструктор-методист | 22 063 |

| | | |
|---|---|---|
| | Спорт буенча инструктор | |
| | Спортчы-инструктор | |
| | Атны йөрергә өйрәтүче тренер | |
| | Спорт техникасын эксплуатацияләү һәм ремонтлау буенча техник | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Күнекмәләр ясау барышы администраторы | 22 070 |
| | Адаптациялиторган физик культура буенча инструктор- методист | |
| | Адаптацияли торган физик культура буенча укытучы тренер | |
| | Хореограф | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Адаптацияли торган физик культура буенча өлкән инструктор-методист | 22 076 |
| | Адаптациялиторган физик культура буенча өлкән укытучы тренер | |
| Өченче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Аналитик (спорт төре яки аның төрләр төркеме буенча) | 22 133 |

2.5. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфаларының база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| “Икенче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Ветеринария фельдшеры | 22 776 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Үсемлекләрне саклау буенча агроном (урта квалификация) | |
| “Өченче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Агроном | 22 826 |
| | Зоотехник | |
| | Ветеринария табибы | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | II категорияле агроном | 22 881 |
| | II категорияле зоотехник | |
| | II категорияле ветеринария табибы | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | I категорияле агроном | 22 936 |
| | I категорияле зоотехник | |
| | I категорияле ветеринария табибы | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Әйдәп баручы агроном | 22 991 |
| | Әйдәп баручы зоотехник | |
| | Әйдәп баручы ветеринария табибы | |
| “Өченче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Баш агроном | 24 223» |

VIII бүлекнең 28 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“28 нче таблица

Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар җитәкчеләренең башкарыла торган эшләренең сыйфаты өчен база окладлары һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләме

| Җитәкченең хезмәте өчен түләү төркеме | Күләм күрсәткеченең зурлыгы (агымдагы елның 1 сентябренә карата дәүләт биреме нигезендә укучылар саны), кеше * | База окладлы, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимул бирү характерындагы түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 0 – 200 | 30 000 | 4 000 |
| 2 | 201 – 400 | 32 000 | 5 000 |
| 3 | 401 – 700 | 36 000 | 5 000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 | 701 – 1 200 | 37 000 | 6 000 |
| 5 | 1 201 – 1 800 | 40 000 | 7 000 |
| 6 | 1 801 һәм аннан да югарырак | 42 000 | 8 000 |

_______________

*Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмада укучылар контингенты (спорт-адаптив мәктәп), 3 коэффициенты белән исәпкә алына.”;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар эшчеләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“II. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар эшчеләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

2.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар эшчеләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|
| “Беренче дәрәҗә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре” һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21 200 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21 398 |
| “Икенче дәрәҗә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре” һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21 539 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21 713 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 21 891 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 22 422 |

2.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфалары гомумтармак һөнәрләренең, һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|
| “Беренче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21 200 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21 398 |
| “Икенче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21 539 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21 713 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 21 891 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 22 118 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 22 304 |
| “Өченче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 22 494 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 22 687 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 22 884 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 23 085 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 23 311 |
| “Дүртенче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 24 223 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 24 423 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 24 623 |

2.3. Хезмәткәр вазыйфасының һәм һөнәренең эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары буенча һөнәри квалификация төркемнәренең квалификация дәрәҗәләренә туры килүе башкарма хакимият федераль органының норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителә.

2.4. Төп урыннан тыш башка урында, шулай ук эш вакыты тулы булмаган шартларда эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә йә башкарылган эшләр күләменә карап гамәлгә ашырыла. Төп вазыйфа буенча, шулай ук төп урыннан тыш башка урында эшләү тәртибендә биләнә торган вазыйфа буенча хезмәт хакы күләмнәрен билгеләү һәр вазыйфа буенча аерым билгеләнә”.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э.Ш. Вафинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.М.Гатиятов**